<table>
<tr>
<td>ГЛАВА ДЫМ-ТАМАКСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>с.Дым-Тамак, ул.Новая, д.4в, 423955</td>
<td>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ<br>Димтамак авылы, Яна урам, 4 в йорт,<br>423955</td>
</tr>
</table>

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz@tatar.ru


**Постановление** **Карар**
**№ 7** **11 ноябрь 2019 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Димтамак авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1. , 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Ютазы муниципаль районының «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. 2019 елның 23 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Димтамак авыл җирлеге Димтамак авылы, Яңа урамы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Димтамак авылы гражданнары җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

"Сез 2020 елда Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Димтамак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, балачактан инвалидлардан, беренче һәм икенче төркем инвалидлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәт итүгә чакырылучылардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- Димтамак авылы Яңа урамы буенча юлны асфальтлауга;

« ӘЙЕ» “ЮК".

3. Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

4. Әлеге карарны ул кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

“Димтамак авыл җирлеге”

муниципаль берәмлеге башлыгы И.А. Сәләмов